| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28.07.2018

№ 126-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге Генераль планы
проекты турында фикер алышу буенча
җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнары проектлары турында фикер алышу мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы мөрәҗәгатен караганнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 24 һәм 28 маддәләре һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 15 маддәсенең 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94нче карары белән расланган “Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә”гә яраклы рәвештә, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районның җирле әһәмияттәге сораулары булуын һәм авыл җирлекләре биләмәләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып һәм халыкның җәмәгать тыңлаулары аша фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Генераль проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрүне 2018 елның 29 августына билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Генераль проекты буенча җәмәгать тыңлауларын түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Молодежная урамы, 8 нче йорт, Шәмәрдән авыл мәдәният йорты бинасы, 13.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Кырбаш авылы, Гагарин урамы, 26 нчы йорт, Кырбаш авыл клубы бинасы, 14.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Мичәнбаш авылы, Советская урамы, 12а йорт, Мичәнбаш авыл клубы бинасы, 15.00 сәгатьтә;

3. Җәмәгать тыңлауларын Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94нче карары белән расланган "Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә"дә билгеләнгән тәртиптә үткәрергә.

4. Фикер алыша торган мәсьәләләр буенча язма тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 нче йорт, 105 каб. адресы буенча тапшырыла ала. Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашуга гариза бирү срогы – 2018 елның 28 августы. Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр язмача яки телдән җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышы вакытында да җиткерелә ала.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

– җәмәгать тыңлаулары үткәрү башлануы турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында, Саба муниципаль районы рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) һәм авыл җирлекләренең авыл җирлекләре бинасы янында җиһазландырылган мәгълүмат такталарында, гражданнар күпләп җыелган урыннарда һәм җирлек биләмәсендәге башка урыннарда, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматларны җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга җиткерүне тәэмин итәрлек башка ысуллар белән халыкка хәбәр итәргә:

1) җәмәгать тыңлауларында каралачак проект һәм аңа кагылышлы мәгълүмати материаллар, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышы яки җыелышларының үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

2) җәмәгать тыңлауларында каралачак проект һәм бу проектка мәгълүмати материаллар исемлеген урнаштыру юлы белән;

3) проект каралачак җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

4) җәмәгать тыңлауларында каралачак проект экспозициясе яки экспозицияләрен ачу урыны, көне; бу проект экспозициясе яки экспозицияләрен үткәрү сроклары, экспозиция яки экспозицияләрне карарга бару мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

5) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан җәмәгать тыңлауларында каралачак проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү тәртибе, срогы һәм формасы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

– Генераль план проекты һәм аңа кагылышлы мәгълүмати материалларны «Интернет» челтәрендә http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга;

– 2018 елның 30 июленнән 29 августына кадәр җәмәгать тыңлауларында каралачак Генераль план проекты экспозициясен Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Молодежная урамы, 8 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында ачарга һәм үткәрергә. Экспозицияне эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр карау мөмкин булачак. Экспозиция эше вакытында килүчеләргә консультацияләр бирү, җәмәгать тыңлауларында каралачак проект турында мәгълүмати материаллар таратуны оештырырга;

– гражданнар һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм хисабын алуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

- 2018 елның 30 июленә кадәр бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында, Саба муниципаль районы рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

– җәмәгать тыңлауларына әзерлекне, җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән срокларда үткәрелүен тәэмин итәргә;

– җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

– «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга;

– Әлеге карарның рәсми төстә басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ